КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 25 декабрь г.Казань № 1684

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында» 2022 ел, 8 апрель, 331 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «алына торган җир кишәрлеген Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенә (кишәрлекләренә) алмаштыру юлы белән» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алына торган җир кишәрлегенең һәм Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) базар кыйммәтен бәяләгәннән соң, 30 көн эчендә җир кишәрлекләрен алышу шартнамәсен (алга таба – шартнамә) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шартнамә төзүне;»;

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацта «имза куелган килешү» сүзләрен «имза куелган шартнамә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында» 2021 ел, 13 декабрь, 1215 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «алына торган җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенә (кишәрлекләренә) алмаштыру юлы белән» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алына торган җир кишәрлекләренең һәм Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) базар кыйммәтен бәяләгәннән соң, 30 көн эчендә җир кишәрлекләрен алышу шартнамәсен (алга таба – шартнамә) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлекләре милекчесенә җибәрүне;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шартнамә төзүне;»;

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацта «имза куелган килешү» сүзләрен «имза куелган шартнамә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин